КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 май г.Казань № 590

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 декабрь, 1280 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә, 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.4. Радиацион, химик һәм биологик характердагы мөмкин булган куркынычлар турындагы, шулай ук аларны локальләштерү буенча күрелә торган чаралар турындагы мәгълүмат, куркынычны ачыклаганнан соң бер сәгатьтән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләр тарафыннан тапшырыла:

учреждениеләргә – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган нәтиҗәләрне бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин